Кукмара муниципаль районы
Чарлы авыл җирлеге Советы

# Карар

2019 елның 28 ноябре № 21

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2014 елның 24 ноябрендәге 30 номерлы
Чарлы авылы җирлеге Советы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Чарлы авылы җирлеге Советы карар бирде:

1. Чарлы авылы җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 30 номерлы карарына (Чарлы авыл җирлеге Советының 2015 елның 29 маендагы 23 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәгеб номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 10 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.2 пунктта:

а) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә карата - 0,2 процент»;

б) 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән Бердәм күчемсез комплекслар;

- төзелеп бетмәгән объектлар, әгәр мондый объектларның билгеләнеше торак йорт булса;»

1.2. алдагы эчтәлекле 3.1 пунктын өстәргә:

«3.1. Физик затларның мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарны;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын;»

Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында \улу\у.prayo.1:a1:ar51ап.ru адресы буенча, шулай ук Чарлы авылы җирлеге торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

Әлеге карар 2О2||р1й1||^ 1 гыйнварыннан, әмма басылып чыккан көненнән соң кимепщ^^Тш^^Ш, үз көченә керә.

Чарлы авыл җирлеге Башлыгы Э.Н.Козлов